## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** 06.12.2019 ел

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Исәнсеф авыл җирлеге составына керүче Яңа Сәет торак пунктына 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлеге Яңа Сәет торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Яңа Сәет торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә. Ялгыз карт гражданнар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар, I, II төркем инвалидлары өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә .

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Яңа Сәет авылында су белән тәэмин итүне ремонтлау һәм төзекләндерү өчен;
- Яңа Сәет авылы территориясендә һәйкәлләрне ремонтлау өчен ;
- Яңа Сәет авылы юлларын кышкы һәм җәйге карап тотуга;
- авыл клубын һәм Яңа Сәет авылы коймасын ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу;
-Яңа Сәет авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, 9 Май, волейбол, яшьләр арасында теннис ярышлары) үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;
- Сабантуй территориясендә электр белән тәэмин итү линияләрен үткәрү өчен кабель сатып алу;
- Яңа Сәет авылы урам яктырткычлары сатып алу;
- Яңа Сәет авылы территориясендә үлән чабу һәм куаклар кисү;

Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырылган: http// muslumovo.tatarstan.ru Мөслим муниципаль районы, Татар Бүләре авылы, Дуслык урамы, 5а йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында да..бар

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татар Бүләр авыл җирлеге башлыгы И.А.Салихов